Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы
Бишмунча авыл җирлеге Бишмунча авылында
гражданнар җыены нәтиҗәләре турындагы карар

26 декабрь 2023 ел

№ 2

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Бишмунча авыл җирлеге Уставының 13.1 статьясы, «Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Бишмунча авыл җирлегенең Бишмунча авылында гражданнар җыены йомгаклары буенча тавыш бирү нәтиҗәләре турында» 2023 елның 26 декабрендәге хисап комиссиясе беркетмәсе нигезендә, Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Әлмәт авыл җирлегенең Бишмунча авылында гражданнар җыены карар бирә:

1. Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Бишмунча авыл җирлегенең Бишмунча авылында 2023 елның 26 декабрендә гражданнар җыены узмаган дип танырга.
2. Әлеге карарны «Альметьевский вестник» газетасында бастырып чыгарырга, Бишмунча авылы, Совет урамы, 57а йорты территориясендә урнашкан махсус мәгълүмат стендларында халыкка игълан итәргә, шулай ук «Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматлар рәсми порталында» (PRAVO.TATARSTAN.RU) һәм Әлмәт муниципаль районы сайты «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштырырга.

Җыенның рәисе, авыл җирлеге
вазифаларын башкаручы М.Ф.Илалов